| ГЛАВА<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.06.2023 п.г.т. Алексеевское № 37

**Алексеевск муниципаль районында хезмәтне саклау буенча Координация советы составына үзгәрешләр кертү турында**

Кадрлар алмашынуга бәйле рәвештә һәм Алексеевск муниципаль районы Башлыгының 21.12.2020 ел, № 94 карары белән расланган Алексеевск муниципаль районында хезмәтне саклау буенча Координация советы турында Нигезләмәнең 7 пунктына ярашлы рәвештә,

**карар бирәм:**

1.Алексеевск муниципаль районы Башлыгының 21.12.2020ел, №94 «Алексеевск муниципаль районында хезмәтне саклау буенча Координация советы турында » карарына 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Гайсин М.Р. | - Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, Совет рәисе |
| Тимонина Н.Ю. | - Татарстан Республикасы Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү министрлыгының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге директоры, Совет рәисе урынбасары (килештерү буенча) |
| Хәмзина Е.А. | - Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, Совет рәисе урынбасары |
| Әхмәтҗанова Д.А. | - инфраструктура үсеше бүлеге белгече, Совет секретаре |
| Фомина Н.А. | - Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура бүлеге башлыгы |
| Курсанова О.А. | - Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Алексеевск муниципаль районында җәмәгать ярдәмчесе (килештерү буенча) |
| Әхмәтҗанов Р.Р. | - Россия Эчке эшләр министрлыгының Алексеевск районы буенча бүлек башлыгы (килештерү буенча) |

| | |
|---|---|
| Хоснетдинов Р.Р. | - ТР буенча Роспотребнадзор идарәсенең Чистай районындагы һәм Чистай шәһәрендәге ТБ ТИ башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Чубачук Ю.В. | - «Алексеевскдорстрой» ААҖ хезмәтне саклау һәм сәнәгать куркынычсызлыгы хезмәте җитәкчесе (килештерү буенча) |
| Җиһаншин М.Р. | - «Алексеевск сөт заводы » ҖЧҖ баш инженеры (килештерү буенча) |
| Михайлов Ю.В. | -Алексеевск районы буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының АХ һәм җитештерү бүлеге консультанты (килештерү буенча) |

2.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммукация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе М. Р. Гайсинга йөкләргә.

**Муниципаль район Башлыгы** **С. А. Демидов**